**Республика Татарстан
Карашай-Сакловское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 нче ел 15 нче март № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитетының 24.12.2015 ел, № 15 карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентның үз көчен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитетының 24.12.2015 ел, № 15 карары белән расланган җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламент үз көчен югалткан дип санау (23 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе В.В.Хусниева